ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.12.2018 Казан ш. № 4-3/г

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Татарстан Республикасында халыкка сатыла торган табигый газга ваклап сату бәяләрен билгеләү турында" 2018 елның 18 июнендәге 4-1/г номерлы карарының 1 пунктына үзгәреш кертү турында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына салымнар һәм җыемнар турында үзгәрешләр кертү хакында" 2018 елның 18 июнендәге 303-ФЗ номерлы Федераль закон чыгарылуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Татарстан Республикасында халыкка сатыла торган табигый газга ваклап сату бәяләрен билгеләү турында" 2018 елның 18 июнендәге 4-1/г номерлы карарының 1 пунктына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"1. Татарстан Республикасы халкына сатыла торган табигый газга ваклап сату бәясен 5,66 сум/куб.м күләмендә (НДСны исәпкә алып) билгеләргә.".

2. Әлеге карарның гамәлдә булу көче 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев